КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 05 февраль г.Казань № 72

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү һәм Татарстан Республикасында граждан-нарга һөнәри юнәлеш бирү чаралары планын раслау турында» 2025 ел, 18 февраль, 96 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү һәм Татарстан Республикасында граждан-нарга һөнәри юнәлеш бирү чаралары планын раслау турында» 2025 ел, 18 февраль, 96 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 19 июнь, 446 нчы, 2025 ел, 12 ноябрь, 937 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацында «2025 елга» сүзләрен «2026 елга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елга Татарстан Республикасында гражданнарның һөнәри юнәлеше буенча чаралар планын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карарның гамәле 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 18 февраль, 96 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 5 февраль, 72 нче карары редакциясендә)

2026 елга Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү чаралары планы

| Т/с | Чара исеме | Максатчан төркем | Үткәрү сроклары | Җаваплы башкаручылар | Гамәлгә ашыру форматы (индивидуаль / төркемле, турыдан-туры / турыдан-турычиттән торып, дистанцион) | Көтелгән нәтиҗәләр һәм күрсәткечләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | «Профессионаллар» һөнәри осталык чемпионатының төбәк этабын һәм Татарстан Республикасының Югары техно- | укучылар, студентлар | 2026 елның I кварталы | ТР Мәгариф министрлыгы* | төркемле, турыдан-туры | эшче һөнәрләренең абруен күтәрү |

*Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 8 нче биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | логияләр чемпионатын үткәрү | | | | | |
| 2. | Үсештә авыр һәм/яки күп төрле бозылулары, шул исәптән акыл үсешендә кимчелекләре булган кешеләр өчен чаралар үткәрү, «Мөмкинлекләр фестивале». | үсештә авыр һәм күп төрле бозылулары булган затлар, акыл үсешендә кимчелекләрен дә кертеп | 2026 елның I – II кварталлары | ТР Мәгариф министрлыгы | төркемле, турыдан-туры | социаллашу, беренчел база һөнәри күнекмәләрне үстерү, социаль мәшгульлеккә ярдәм итү, җәмәгать оешмаларын авыр һәм/яки күптөрле үсеш бозулары, шул исәптән акыл үсешендә кимчелекләре булган кешеләргә озатып йөрүче эш белән тәэмин ителешкә ярдәм итү мәсьәләләренә җәлеп итү |
| 3. | «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының төбәк этабын үткәрү | эшләүче һәм укучы яшьләр | 2026 елның II кварталы | ТР Хезмәт, халыкны социаль яклау министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы, ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, ТР Төзелеш министрлыгы, ТР Транспорт министрлыгы, ТР Цифрлы үсеш министрлыгы, ТР | төркемле, турыдан-туры | эшче һөнәрләренең абруен күтәрү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Яшьләр эшләре министрлыгы | | |
| 4. | «Һөнәре буенча иң яхшысы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының «Радиоэлектрон җиһазлар монтажчысы» номинациясендә федераль этабын үткәрү | эшләүче һәм укучы яшьләр | 2026 елның II – III кварталлары | ТР Хезмәт, халыкны социаль яклау министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, ТР Цифрлы үсеш министрлыгы, ТР Яшьләр эшләре министрлыгы | төркемле, турыдан-туры | эшче һөнәрләренең абруен күтәрү |
| 5. | «Мәктәп бизнес-стартапы» республика проектын үткәрү | укучылар | 2026 елның II кварталы | ТР Мәгариф министрлыгы | төркемле, турыдан-туры | эшмәкәрлек фикерләве, презентация, дәлилләү, планлаштыру күнекмәләрен формалаштыру, үз проектларын үстерү |
| 6. | Инвалидлар һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» төбәк чемпионатын үткәрү | инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар | 2026 елның II кварталы | ТР Мәгариф министрлыгы | төркемле, турыдан-туры | җәмгыятьтә аларны эшкә урнаштыруга һәм социаль-мәдәни инклюзиягә ярдәм итү максатларында инвалидлыгы булган кешеләрнең һөнәри белем алуга нәтиҗәле профессиональ ориентациясен һәм мотивациясен үстерү |
| 7. | «Россиядә эш. Мөмкинлекләр вакыты» бөтен- | эш эзләүче граждан- | 2026 елның II кварталы | ТР Хезмәт, социаль яклау | төркемле, турыдан-туры | гражданнарга – эшкә урнаштыруда, ә эш бирүчеләргә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | россия эшкә урнашу ярминкәсен оештыру | нар, чыгарылыш курс студентлары | | министрлыгы | | кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү |
| 8. | «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион эшләүче яшьләр иҗаты фестивален үткәрү | эшләүче яшьләр | 2026 елның IV кварталы | ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, ТР Яшьләр эшләре министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы | төркемле, турыдан-туры | яшьләрнең үз-үзләрен тормышка ашыру мөмкинлеген булдыру |
| 9. | Татарстан Республикасында төзелә торган Уникаль осталык үзәге нигезендә һөнәри юнәлеш үзәген булдыру | укучылар | 2026 елның IV кварталы | ТР Мәгариф министрлыгы | төркемле, турыдан-туры | чыгарыш укучыларына аңлы социаль-һөнәри үзбилгеләүдә, уку йорты, һөнәр сайлауда һәм һөнәри юнәлеш компетенцияләрен формалаштыруда ярдәм итү |
| 10. | 8 – 10 сыйныф укучылары өчен «ProSkills: Һөнәрне сынап кара һәм сайла» һөнәри юнәлеш бирү чарасын үткәрү | укучылар | 2026 ел дәвамында | ТР Мәгариф министрлыгы | төркемле, турыдан-туры | һөнәри өлкәдә сәләтләр һәм кызыксынуларны ачыклау. Хәзерге хезмәт базары турында күзаллау формалаштыру |
| 11. | «Ел инженеры» республика конкурсын уздыру | эшләүче яшьләр, студентлар | 2026 ел дәвамында | РТ Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | төркемле, турыдан-туры | инженер хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын һәм хезмәтләренең җәлеп итүчәнлеген арттыру |
| 12. | Халыкара төзелеш чемпионатында катнашу | эшләүче яшьләр | 2026 ел дәвамында | ТР Төзелеш министрлыгы | төркемле, турыдан-туры | һөнәри күнекмәләрне күрсәтү, хезмәттәшләр белән тәҗрибә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | уртаклашу, алдынгы техноло-гияләрне үзләштерү |
| 13. | «Безне чолгап алган һөнәрләр дөньясы» агарту чарасын үткәрү | мәктәпкәчә яшьтәге балалар, башлангыч сыйныф укучылары | 2026 ел дәвамында | ТР Мәгариф министрлыгы | төркемле, турыдан-туры | иҗади сәләтләрне үстерү, үз нәтиҗәләреңне күрсәтә белү, балаларда һөнәрләрнең күп-төрлелегенә иртә кызыксыну формалаштыру һәм аларның һөнәри үзбилгеләнүенә ярдәм итү |
| 14. | Һөнәри юнәлеш бирү чараларын үткәрү:<br>«Киләчәкнең IT-инже-нериясе» конкурсы;<br>«Киләчәк инженерлары – Радист» конкурсы;<br><br>В.А.Окулов исемендәге авиация төзүче олимпиа-дасы | <br><br>студентлар<br><br>студентлар<br><br>укучылар | <br><br>2026 елның I кварталы<br><br>2026 елның I – II квартал-лары<br><br>2026 елның II кварталы | «КНИТУ – КАИ» ЮБ ФДБМУ (килешү буенча) | <br><br>төркемле, турыдан-туры<br><br>төркемле, турыдан-туры<br><br>төркемле, турыдан-туры | <br><br>интеллектуаль иҗатны үстерүне стимуллаштыру<br><br>яшьләрнең электроника, про-граммалаштыру, телекомму-никация өлкәсендә фәнни-тикшеренү, иҗади эшчәнлеккә (проектларга) кызыксынуын формалаштыру<br><br>максатчан укыту өчен кандидатлар сайлаганда олимпиадада катнашучыларның нәтиҗәләрен исәпкә алу |
| 15. | Һөнәри юнәлеш бирү чараларын үткәрү:<br>«КНИТУның Нобель өметләре – 2026» | <br><br>укучылар, студентлар | <br><br>2026 елның I – II | «КНИТУ – КАИ» ЮБ ФДБМУ (килешү буенча) | <br><br>индивидуаль, төркемле, | <br><br>укучыларның проект эшчән-леген гамәлгә ашыруга |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | конкурсы; | | квартал-лары | | турыдан-туры - читтән торып | юнәлтелгән интеллектуаль иҗатын үстерүне стимуллаштыру |
| | «Чиксез фән» фәнне популярлаштыручылар конкурсы; | укучылар, студентлар | 2026 елның I кварталы | | индивидуаль, төркемле, турыдан-туры - читтән торып | укучыларда танып белү, иҗади, эксперименталь-тикшеренү, проект эшчәнлегенә кызыксыну формалаштыру |
| | «Зур химиянең киләчәге» Идел буе төбәкара олимпиадасы | укучылар, студентлар | 2026 елның I – II квартал-лары | | индивидуаль, турыдан-туры - читтән торып | иҗади сәләтләрне һәм фәнни эшчәнлеккә кызыксынуны үстерү, фәнни белемнәрне пропагандалау |
| 16. | Һөнәри юнәлеш бирү чараларын үткәрү: | | | КДАТУ (килешү буенча) | | |
| | «Яшь инженер», «Яшь архитектор» олимпиадалары; | укучылар | 2026 елның I кварталы | | төркемле, турыдан-туры, дистанцион | КДАСУ укырга кергәндә кандидатларны сайлаганда олимпиадада катнашучыларның нәтиҗәләрен исәпкә алу |
| | мастер-класслар | укучылар | 2026 елның II кварталы | | төркемле, турыдан-туры | әзерлекнең аерым юнәлешләрен популярлаштыру |
| 17. | Һөнәри юнәлеш бирү чараларын үткәрү: | | | КФУ ЮБ ФДАМУ (килешү буенча) | | |
| | «Лобачевский. Үтеп керү» фәнни тикшеренүләр конкурсы; | укучылар | 2026 елның I кварталы | | индивидуаль, төркемле, турыдан-туры | реаль икътисад секторыннан кейслар чишү аша, шулай ук фәнни-тикшеренү һәм проект |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | эшләрен башкару аша һөнәри өлкәдә сәләтләр һәм кызык-сынуларны ачыклау. КФУ ЮБ ФДАМУ укырга кергәндә өстәмә баллар бирү |
| | «Менделеев варислары» химия һәм химия техно-логиясе буенча мәктәп укучылары олимпиадасы; | укучылар | 2026 елның I кварталы | | индивидуаль, турыдан-туры | химия һәм химик технология буенча биремнәрне үтәү аша һөнәри өлкәдә сәләтләр һәм кызыксынуларны ачыклау. КФУ ЮБ ФДАМУ укырга кергәндә өстәмә баллар бирү |
| | Россия халыкларының туган телләре һәм әдә-биятлары буенча мәктәп укучылары өчен федераль олимпиада; | укучылар | 2026 елның I кварталы | | индивидуаль, турыдан-туры | ике телле укытучылар әзерләүгә ярдәм итү. КФУ ЮБ ФДАМУ укырга кергәндә өстәмә баллар бирү |
| | «Милли технология олимпиадасы» бөтен-россия күптармаклы мәк-тәп укучылары олим-пиадасы. «Конструктив куркынычсызлык» профиле; | укучылар | 2026 елның II кварталы | | төркемле, турыдан-туры | конструктив куркынычсызлык буенча биремнәрне үтәү аша һөнәри өлкәдә сәләтләр һәм кызыксынуларны ачыклау. КФУ ЮБ ФДАМУ укырга кергәндә өстәмә баллар бирү |
| | «КЛЮЧ-КАЗАНЬ» төбәк кейс-чемпионаты; | укучылар, студентлар | 2026 елның IV | | төркемле, турыдан-туры | эшмәкәрлек буенча кейслар чишү. Стартаплар презентациясе. |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | КФУ ЮБ ФДАМУ төбәкара предмет олимпиадалары | укучылар, студентлар | кварталы<br><br>2026 елның IV кварталы | | индивидуаль | КФУ ЮБ ФДАМУ укырга кергәндә өстәмә баллар бирү<br><br>24 профиль буенча биремнәр үтәү аша һөнәри өлкәдә кызыксынуларны һәм сәләтләрне ачыклау (шул исәптән «Автомобиль төзелеше», «Психология һәм педагогика», «Икътисад», «Хокук» һ.б.). КФУ ЮБ ФДАМУ укырга кергәндә өстәмә баллар бирү |
| 18. | Һөнәри юнәлеш бирү чараларын үткәрү:<br>Урта һөнәри уку йортлары укучылары арасында III бөтенроссия фуд-дизайн объектлары арт-күргәзмәсе;<br><br>Россия Федерациясендә җирле үзидарә көненә багышланган олимпиада | студентлар<br><br>укучылар, студентлар | 2026 елның I кварталы<br><br>2026 елның II кварталы | КИУ (килешү буенча) | төркемле, турыдан-туры<br><br>индивидуаль, төркемле, турыдан-туры | катнашучыларның иҗади сәләтләрен һәм һөнәри компетенцияләрен үстерү, инновацион фуд-дизайнга кызыксынуны арттыру<br><br>укучыларда сәяси культураны, гражданлык өлгергәнлеге формалаштыру һәм патриотик кыйммәтләрне үстерү. Укучыларның иҗади потенциалын тормышка ашыру, педагогик хезмәткәрләрнең мотивациясен һәм иҗади активлыгын арттыру |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ТР Мәгариф министрлыгы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

ТР Хезмәт, социаль яклау министрлыгы – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;

ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы - Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы;

ТР Төзелеш министрлыгы – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;

ТР Транспорт министрлыгы – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы;

ТР Цифра министрлыгы – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;

ТР Яшьләр министрлыгы –Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;

ТР Икътисад министрлыгы - Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

«КНИТУ – КАИ» ЮБ ФДБМУ – «А.Н.Туполев ис. Казан милли тикшеренү техник университеты - КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе;

«КНИТУ» ЮБ ФДБМУ – «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе;

КДАТУ – «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем мәгариф учреждениесе;

«КФУ» ЮБ ФДАМУ – югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе;

КИУ – «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты (ИЭУП)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесе.